

Рузаевка районы Татар Пешлә авылында булып кайттым. Жәй, табигать матур, коннен һава торышы да кvнелләрне кvтәрә иде.Командировкамны унышлы йомгаклыйм дигәндә тагы очрашу - матур гаилә, хезмәт яраткан кешеләр белән булды. Ул – Пешлә авылынын Садовая урамында гомер итvче Саитовлар гаиләсе.
Белгәнебезчә, ел саен 8 июль конне илебездә Россиякvләм Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык коне билгеләп vтелә. Беренче тапкыр әлеге бәйрәм гаилә елы дип 2008 елда vтте. Исегезгә тошерәбез, Халыкара Гаилә коне ел саен 15 май конне билгеләп vтелә. Шул унайдан тагы бер матур гаилә турында язарга булдым.       Гаилә -һәр кешенен таяныр ноктасы, ә гаиләнен татулыгы -ир белән хатыннын ижат жимеше. Жылы учагын, сагынып котәр пар канатын, юатучын булса, тирә-ягында балаларын ботерелеп йорсә, синен жанын тыныч. Танышканда Рәшидә Мусалим кызы Саитова шундыйларнын берсе дип тоелды. Һәм чыннан да шулай.
Рәшидә Мусалим кызынын тормыш иптәше Саитов Адель Хусаин улы гомере буе Рузаевка тимер юл челтәрендә машинист булып хезмәт итә. Туган жирендә vз нигезенне булдыру гаиләнен ныклы булуын исбатлый. Ирле-хатынлы Саитовлар да әнә шулай икесе дә тырыш, унган, булдыклы кешеләр. Алар бергә дус-тату яшәп ике бала тәрбиялиләр. Алар ойләнешеп, тормыш коруына да берничә дистәдән артык гомер узып киткән инде. Ирле-хатынлы икәvләшеп хезмәтләреннән ямь табып, дәрт алып яши. Үз кочләре белән тырышып, зур, якты йорт салып чыгалар. Ихата тутырып мал асралуы, бакчадагы жиләк-жимеш муллыгы да бирелдә жин сызганып, тир тvгеп, тырышып гомер итvче  гаилә яшәвен исбатлый. Халык телендәге “Ир унса – хатыннан, хатын уна – ирдән” дигән әйтем дә бу гаиләгә тобәп әйткән сыман. Ә Саитовлар икесе дә бер-берсеннән унган. Алар анлашып, бер-берсенә юл куешып, тату гомер итә.
Житез, унган хужабикә Рәшидә Мусалим кызы Саитова 40 ел кулинария кибетендә сатучы булып эшләгән. Бvген лаеклы ялда. Кибетче һонәрен жинел эш дип уйлаучылар бар: алай тvгел икән шул. Калькуляторы кулында булса да, кибетчегә бит әле зиһен, чаялык, житезлек, сабырлык та кирәк. Ялгыш санап «остенә чыгуы» да ихтимал. Кешеләр белән аралаша белергә дә тиешсен. Менә шул сыйфатларны vзендә булдырып, тырышып хезмәт иткән Рәшидә сатучы. Һәр нәрсәгә теләк, тумыштан килгән сәләт кирәк шул. Шул ук печенье - пирожки сату очен дә…

Гаиләдә Рәшидә тыныч холыклы, оста куллы хужабикә, яраткан балаларына жан атып торучы ягымлы, назлы әни, ә тормыш иптәше очен сойкемле, унган хатын да, зур терәк тә. Тату гаиләдә балалар да зирәк, эшсояр булып vсә. Менә инде тугыз елдан артык Рәшидә Мусалим кызы Саитова ике улы, ике килене, оныклары белән бергә, бер йортта гомер иткән кеше. Наиль улы, Рузаевка тимер юл вокзалында дежурный булып эшли. Хатыны Галия – балалар бакчасында тәрбияче. Оныгы Альмирга 6 яшь. Икенче улы Ринат, тормыш иптәше Эльвира (шәһәр администрациясе хезмәткәре) белән әле генә Рузаевка шәһәрендә квартир алып яши башлаганнар икән. Әлегә кадәр алар да әни-әтиләре белән бергә яшәгәннәр. Шулай итеп, бер йортта оч гаилә тату яши алган һәм ала! Бvген актуаль мәсьәләләрнен берсе булган кайнана белән килен проблемалары аларда юк. Бу яктан да гаилә ундырган.
Рәшидә Мусалим кызына эшкә мәхәббәт туган гаиләсендә ойрәтелә. Әнисе - Раисә Закировна, Татар Пешләсенен алдынгы “Россия” колхозында ярты гасырга якын сот сава, шул ук вакытта балалар тәрбияли, ой  жыештыра, мал-туар асрый. Гомере буе Пешләдә яшәгән Раисә Закир кызы Чугуновага тиздән 84 яшь тула.Матур яшәп матур гомер итә ул. «Без барыбыз да бер тирәдә, Садоваяда яшибез. Без дигәнем, ике сенел, ике брат (беребез бакый доньяга кvчте)  һәм әниебез”, - ди Рәшидә ханым туган гаиләсе турында.
Татар халкына хас булган кунакчыллык Рәшидә ханымда да: ул чәй эчәргә кыстады. Әмма татар авылы йорты капкасы алдындагы диванда, саф һава сулый-сулый, авыл хәлләре турында сойләшеп утыруны хуш кvрдем мин. Без аралашкан арада яныбызга якынлашкан бер карчыкны кvрдем һәм бу авылга хас шундый диалог ишеттем. Рәшидә ханым әбине кvргәч:
- Тетя Аня, здравствуйте, за хлебом ходили?
- Да, Рашидя. Здравствуйте! У меня к тебе одна просьба есть: вот мой долг отдай нашей соседке, когда увидишь. Я никак не встречусь с ней.
- Да сама отдаш.
-А какая разница – ты или я отдам?
Мин бу сvзләрдән сон бер нәтижә ясадым: бу авылда торле милләт халкы дус, бер-берсенә ышанып, ярдәмләшеп яши, икән. Дуслык турындагы сvзләрдән сон яшәv шартлары темасын кvтәрдек.
- Татар Пешләсе авылыбызда яшәве дә унай: ойләргә vзәк водопроводтан су кертелгән, асфальт юллар, мусор баклары...шәһәрдә торган тосле яшибез. Ә Рузаевка шәһәре – урамыбызнын икенче башыннан башланып китә, - ди әнгәмәдәшем Рәшидә ханым. – Хужалык эшләре белән шогыльләнергә шартлар бар. Каз-vрдәк кvпләп асрыйм. Мона артыбыздагы Пешлә елгасы унайлы.
Авыл хәлләре, гаилә тормышы турында сvз алып барганда, мин кисәк кенә традицион сорау бирдем Рәшидә Мусалим кызына: “Сез гаиләгезне бәхетле дип санныйсызмы?” Бераз уйланып торгач: “Безнен йорт - безне саклаучыбыз, жылы учагыбыз. Анда һәрвакыт туры юл кvрсәтvче, шәфкатьлелек орлыкларын индерvче, vзара монәсәбәтләрне жайлаучы ялкын булырга тиеш. Гаиләдәге vзара монәсәбәтләр бер-беренә мәхәббәт, ышаныч, vзара анлашуларга нигезләнә. Бары шул чакта гына гаиләдә һәркем vзен чын мәгънәсендә бәхетле итеп тоя ала”, - ди Рәшидә Мусалим кызы Саитова.
Менә шулай матур, бердәм һәм тату гаилә булып Татар Пешләсе авылында гомер итә эшчән Саитовлар.

**Наилә Насырова**